**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                 КАРАР

__________                    ПР-129 02.06.2025                    № _____

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Әгъбәс башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен бетерү турында**

Россия Федерациясе Граждан кодексының 61-64 статьялары, «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында» 124-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктына таянып, Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссиянең 28.05.2025 ел, 31 номерлы бәяләмәсе, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Әгъбәс авылы гражданнар җыелышының 13.03.2025 ел, 1 номерлы беркетмәсе нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Әгъбәс башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен 2025 елның 31 июленнән бетерергә.
2. «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсе «Әгъбәс башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесе документларын саклау һәм мөлкәтен кабул итү өчен җаваплы хокукый варисы итеп «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесен билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе структур бүлекчәсе «Әгъбәс башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесе ликвидаторы итеп «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Д.Ф.Нәбиеваны билгеләргә.
4. «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры Д.Ф.Набиевага:

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына үзгәреш проектын әзерләргә;
- бетерелә торган гомуми белем бирү учреждениесенең штатларын хезмәт законнары нигезендә кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;
- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсе «Әгъбәс башлангыч мәктәбе» белем бирү учреждениесен законда билгеләнгән тәртиптә тиешле хезмәтләрдә бетерергә;

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенә 1-4 сыйныф укучыларын йөртү эшен оештыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.М.Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче И.Ш.Бариев